СОВЕТ
ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ**
23.12.2015

Зеленодольск ш.

**КАРАР**
№ 39

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегендә 2009 елның 23 декабрендәге 184 номерлы карары белән расланган территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 34 статьясындагы 3 өлеше, «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставының 42 статьясындагы 1.2 пункты, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге уставының 6 статьясындагы 3 пункты нигезендә, муниципаль хокукый актлар системасын актуальләштерү максатларында Зеленодольск шәһәре Советы **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәренең 2009 елның 23 декабрендәге 184 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру тәртибе турындагы нигезләмәгә (2012 елның 16 мартындагы 96 номерлы Зеленодольск шәһәре Советы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән), түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1) 5 статьяда:

1.1) 2 пунктның 1 бүлегендә «Шәһәр башлыклары һәм Зеленодольск шәһәре Башкарма комитеты адресына» сүзләрен «Зеленодольск шәһәре мэры һәм Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты адресына» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта «Зеленодольск шәһәре Башкарма комитеты» сүзләрен «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты» сүзләренә алмаштырырга;

2) 6 статьяның 7 пунктында «Шәһәр башлыгы» сүзләрен «Зеленодольск шәһәре мэры» сүзләренә алмаштырырга;

3) 7 статьяның 1 пунктының алтынчы абзацында «Зеленодольск шәһәре Башкарма комитеты» сүзләрен «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты» сүзләренә алмаштырырга;

4) 8 статьяның 5 пунктында «Зеленодольск шәһәре Башкарма комитеты» сүзләрен «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты» сүзләренә алмаштырырга;

5) 10 статьяда:

5.1 пунктта «Шәһәр башлыгына» сүзләрен «Зеленодольск шәһәре мэрына» сүзләренә алмаштырырга;

5.2 пунктта «Зеленодольск шәһәре башлыгы» сүзләрен «Зеленодольск шәһәре мэры» сүзләренә алмаштырырга;

5.3) 5 пунктта:

5.3.1) «Шәһәр башлыгы» сүзләрен «Зеленодольск шәһәре мэры» сүзләренә алмаштырырга;

5.3.2) «шәһәрнең Башкарма комитеты» сүзен «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты» сүзләренә алмаштырырга;

5.4) 8 пунктта «Зеленодольск шәһәре башлыгы» сүзләрен «Зеленодольск шәһәре мэры» сүзләренә алмаштырырга;

14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Территориаль иҗтимагый үзидарә Уставларын теркәү турындагы белешмәләр территориаль үзидарә Уставлары реестрында чагыла, ул Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратын документлар белән тәэмин итү бүлеге тарафыннан алып барыла һәм шушы бүлектә саклана»;

6) 13 статьяның 1 пунктындагы 4 пунктчасында «Шәһәр башлыгына һәм Зеленодольск шәһәре Башкарма комитетына» сүзләрен «Зеленодольск шәһәре мэрына һәм Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына» сүзләренә алмаштырырга;

7) 20 статьяның 5 пунктында «Зеленодольск шәһәре Башкарма комитеты» сүзләрен «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә урнаштырырга.

**Зеленодольск шәһәре мэры,**
**Совет рәисе** **А.В. Тыгин**